# СҮЗЛЕКНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ ТУРЫНДА

1. Баш сүзләрне бирү тәртибендә абсолют **алфавит принцибы** нигез итеп алынды.

2. **Сүзлек мәкаләсе**нең башында милләт атамасының русча варианты күплек сан формасында, аннан соң кыек сызык аша берлек санда килә. Алар баш хәрефтән куе шрифт белән бирелде. Аннан соң шул ук тәртиптә татарчалары шулай ук баш хәрефтән, ачык шрифт белән күрсәтелде. Һәр сүзгә басым куелды. Аннан соң тиешле тамгалар һәм татар телендә аңлатма китерелде, ноктaлы өтер аша үзатама бирелде. Халыкның үзатамасы чыганакларда күрсәтелмәгән очракта яки рәсми атамасы белән туры килгәндә, ул бирелмәде.

3. Халыкның атамасы рус теле аркылы кереп, татар телендә аның билгеле **язылыш** традициясе булса, ул элеккe язылышында калдырылды. Ә милләт атамаларының татар телендә ныклап урнашкан эквиваленты булмаган очракларда, бу атамаларны татар теленә тәрҗемә иткәндә халыкның телен дә исәпкә алып, үзатамасына мөмкин кадәр якын яңгырашын сакларга тырышылды. Мәсәлән:

**АБХА́ЗЫ / АБХА́З** АБХАЗЛА́Р / АБХА́З...
**АУ́ХОВЦЫ / АУ́ХОВЕЦ** ОВХОЙЛА́Р / ОВХО́Й...

4. Кечерәк этник берәмлекләрне белдергән сүзләрнең мәкаләсе ахырында, аның нинди халыкка, нинди зуррак бергәлеккә каравын күрсәтү өчен, *к.* тамгасы белән зуррак берәмлекне белдергән атамага сылтама ясалды. Мәсәлән,

**ТЕМИРГО́ЕВЦЫ** / ТИМЕРГОЙЛА́Р .... *к.* **адыги**.

Бик сирәк очракларда этник төркем берьюлы ике халыкка нисбәт ителә, сүзлектә аларның икесенең дә исеме бирелде:

**БО́ЙКИ** / **БОЙК** БО́ЙКЛАР / БОЙК Украин (яки русин) халкының Көнбатыш Украинада яшәүче, украин, словак телләрендә сөйләшүче, христиан диненең православие юнәлешен тотучы этник төркеме; үзатамалары: **верховинцы**, **горальцы**, **подгоряне**; *к.* **русины** *һәм* **украинцы**.

5. Һәр мәкалә һәм һәр **мәгънә** яңа юлдан башлана. Мәгънәләр җәяле гарәп цифры белән аерыла. Мәкалә ахырында нокта куела:

**МА́ВРЫ** / **МАВР** МАВРЛА́Р / МАВР 1) *тар*. Римлылар тарафыннан Мавританиянең төп халкын атау өчен кулланылган экзоэтноним;

2) *тар*. VII–XVII гасырларда борынгы Мавританиядә яшәгән төп халык;

3) *тар*. Урта гасырларда исламны тотучы Пиреней ярымутравының һәм Төньяк Африканың көнбатышындагы Африка кабиләләрен һәм бәрбәрләрне берләштергән гомуми атама;

4) *иск*. VII–XVII гасырларда яшәгән теләсә нинди кара тәнле халык;

5) *к*. **мавританцы**.

6. Халыкларның катлаулы структурасын, аларны тәшкил иткән төрле дәрәҗәдәге төркем, кабилә, ыру кебек берәмлекләрнең үзара мөнәсәбәтен һ. б. ны адекват чагылдыру өчен, махсус **тамгалар** һәм сылтамалар системасы кулланылды. Һәр тамганың билгеләнеше, алга таба куллану очрагы белән бергә, мисаллар китереп аңлатыла.

7. Күп кенә очракта халыкның билгеле, киң таралган, гадәттә русчалаштырылган язылышлы атамасы да, үз телендәге яки шуңа якын **үзатамасы** да теркәлде. Алар алфавит тәртибендә, һәркайсы үз урынында бирелде һәм һәр икесендә бер-берсенә сылтама ясалды.

**АБАДЗЕ́ХИ / АБАДЗЕ́Х** АБЫДЗАХЛА́Р / АБЫДЗА́Х ...; үзатамасы: **абдзахи**...

**АБДЗА́ХИ / АБДЗА́Х** АБДЗАХЛА́Р / АБДЗА́Х Үзатама; *к.* **абадзехи**.

8. Сүзлектә, бер үк милләтне белдергән **синонимик** атамаларны теркәгәндә дә, шул ук принципка таянылды һәм бер вариантында гына аңлатма бирелеп, икенчесенә *к. ш. ук* тамгасы белән сылтама җибәрелде. Әгәр синонимнар саны икедән артса, аңлатма ешрак кулланылган, киңрәк таралган вариантында китерелде һәм махсус билге (*) белән күрсәтелде.

**АЗАРА́ / АЗАРА́** АЗАРАЛА́Р / АЗАРА́ *к. ш. ук* **хазара***, **хезаре**.

9. Халыкның уртак үзатамасы булмаган, этник төркемнәрнең **локаль үзатама**лары хезмәтен генә үтәгән этнонимнар бар. Башка кайбер очракларда халыкның, ыруның бер генә түгел, берничә үзатамасы булырга мөмкин. Мәсәлән:

**АКАГА́И / АКАГА́Й** АКАГАЙЛА́Р / АКАГА́Й Алеут халкының Дүртсопкалы утрауларда яшәүче локаль төркеменең үзатамасы...

**АМИГУ́НЫ / АМИГУ́Н** АМИГУННА́Р / АМИГУ́Н Алеут халкының Андреянов утрауларында яшәүче локаль төркеменең үзатамасы...

10. Халыкларның хәзерге көндә кулланылмаган, искергән атамалары *иск.* тамгасы белән, аңлатма бирмичә, *к.* сылтамасы белән аңлатмасы булган хәзерге атамасына җибәрелде. Мәсәлән:

**АБА́СКИ / АБА́СК** АБА́СКЛАР / АБА́СК *иск. к.* **абадзехи**.

**ГИЛЯКИ́ / ГИЛЯ́К** ГИЛЯКЛА́Р / ГИЛЯ́К *иск. к.* **нивхи**.

Кайбер искергән атамаларның кабат кулланыла башлавы күзәтелсә дә, алар сүзлектә шул ук *иск.* тамгасы белән теркәлде, чөнки аларның киң таралган, активрак синонимы бар:

**ГО́ЛЬДЫ / ГОЛЬД** ГО́ЛЬДЛАР / ГОЛЬД *иск. к.* **нанайцы**.

11. Хаталы сүзләрне, **ялгыш** куллану очракларын күрсәтү өчен, шул ук принципка таянылды, *ялг.* тамгасы куелды һәм

аңлатмасы булган дөрес вариантына *к.* сылтамасы белән җибәрелде:

**НАВА́ХИ** / **НАВА́ХИ** НАВА́ХИЛАР / НАВА́ХИ *ялг. к.* **навахо**.

12. **Омонимнар** халык атамалары арасында сирәк булса да очрый. Алар аерым мәкаләләр итеп, рим цифрлары белән бирелде. Мәсәлән:

**МАЛИ́ЙЦЫ I** / **МАЛИ́ЕЦ** МА́ЛИЯЛЫЛАР / МА́ЛИЯЛЫ *тар.* Борынгы Грециянең Малия регионында яшәгән...

**МАЛИ́ЙЦЫ II** / **МАЛИ́ЕЦ** МАЛИЛЫЛА́Р / МАЛИЛЫ́ Көнбатыш Африканың Мали Республикасында яшәүче... халыклар бергәлеге...

13. Кайбер атамаларның татар телендә **ике варианты** очравы ачыкланды. Ул вариантлар икесе дә дөрес, урынлы булганда, алар өтер аша бирелде. Мәсәлән,

**АГИ́НСКИЕ БУРЯ́ТЫ** / **АГИ́НСКИЙ БУРЯ́Т** АГЫ́Н БУРЯТЛАРЫ́, АГА́ БУРЯТЛАРЫ́ / АГЫ́Н БУРЯТЫ́, АГА́ БУРЯТЫ́...

Бу атама Ага елгасы белән бәйле булу сәбәпле, **Ага бурятлары** варианты алынды, елганың исеме бурятча Агын булганга һәм үзатамада да чагылганга, **Агын бурятлары** варианты да теркәлде.

Шундый ук очрак:

**АЧИ́НЫ I** / **АЧИ́Н** АЧИННА́Р, А́ЧАЛАР / АЧИ́Н, А́ЧА Шор халкының бер ыруы...

14. Бик сирәк кенә очракта бер рус атамасының төрле мәгънәләре татарча төрле сүзләр белән белдерелә, алар сүзлектә, гарәп цифрлары белән аерып, түбәндәгечә бирелде:

**СКАНДИНА́ВЫ** / **СКАНДИНА́В** СКАНДИНАВЛА́Р / СКАНДИНА́В 1) *тар.* Скандинавиядә яшәгән борынгы төньяк герман кабиләләре;

2) СКАНДИНА́ВИЯЛЕЛӘР / СКАНДИНА́ВИЯЛЕ Скандинавия ярымутравында һәм аңа якын утрауларда яшәүче,

төньяк герман телләрендә сөйләшүче швед, норвег, дат, исланд халыкларын берләштергән гомуми атама.

**ГОЛЛА́НДЦЫ / ГОЛЛА́НДЕЦ** ГОЛЛАНДЛА́Р / ГОЛЛА́НД 1) Голландиядә (Нидерландта) яшәүче, нидерланд телендә сөйләшүче, күпчелеге христиан диненең протестантизм, католицизм юнәлешләрен тотучы халык; *к. ш. ук* **нидерландцы**;

2) ГОЛЛА́НДИЯЛЕЛӘР / ГОЛЛА́НДИЯЛЕ Нидерландта һәм аның иң зур провинциясе Голландиядә яшәүче барлык халыклар.

15. Атамалар арасында үзара охшаш, **аваздаш**, ләкин мәгънәләре белән нык аерылып торган атамалар да еш очрый. Аермасын ачык күрсәтү һәм куллануда ялгышларны булдырмау өчен, алар *чаг.* сылтамасы белән бер-берсенә җибәрелде. Мәсәлән:

**АВА́РЦЫ / АВА́РЕЦ** АВАРЛА́Р / АВА́Р Башлыча Дагстанда яшәүче, нах-дагстан телләренең берсендә сөйләшүче, исламның сөнни мәзһәбен тотучы асаба халык; үзатамасы: **аваралы**; *чаг.*: **авары**.

**АВА́РЫ / АВА́Р** АВА́РЛАР / АВА́Р *тар*. Үзәк Азиядән чыккан, VI гасырда, Үзәк Европага күчеп, анда Авар каганаты (VI–IX гг.) төзегән, төрле гипотезаларга караганда я монгол, я иран, я төрки телдә сөйләшкән күчмә халык; *чаг.*: **аварцы**.

Сүзлектән куллануны җиңелләштерү максаты белән, кушымта итеп татар атамаларының алфавит күрсәткече бирелде.